РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
ТЕТЮШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422370 г.Тетюши, ул.Малкина, 39

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТӘТЕШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
422370 Тәтеш шәһәре, Малкин ур, 39

тел. (84373) 2-50-02, 2-53-33, факс 2-62-48, e-mail: tatesh@tatar.ru
ОКПО 78702097, ОГРН 1061672000037, ИНН/КПП 1638004978/163801001

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**24 .06. 2024** **№ 49-4**

**Тәтеш муниципаль районы Советының "Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының хезмәт (вазыйфаи) үз-үзен тотышына таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турында Нигезләмәне раслау хакында" 25.02.2019 елның 39-4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Советы карар кылды:

1. Тәтеш муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының хезмәт (вазыйфаи) үз-үзен тотышына таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турында Нигезләмәне раслау хакында» 25.02.2019 ел, № 39-4 карарына 2 нче кушымтага үзгәрешләр кертергә һәм аны яңа редакциядә расларга (кушымта итеп бирелә).
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча Интернет урнаштырырга: http://tetushi.tatarstan.ru/.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы башлыгы урынбасары Е.Г. Курковка йөкләргә.

**Татарстан Республикасы**
**Тәтеш муниципаль районы**
**башлыгы** **Р.Х. Сафиуллов**